| | | |
|---|---|---|
| МИНИСТЕРСТВО<br>ЛЕСНОГО ХОЗЯЙСТВА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>УРМАН ХУҖАЛЫГЫ<br>МИНИСТРЛЫГЫ |

ПРИКАЗ БОЕРЫК

12.04.2019 г.Казань № 318-осн

2019 елның 12 февралендәге 80-осн номерлы боерык белән расланган Әлки урманчылыгы урман хуҗалыгы регламентына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы норматив хокукый актын законнарга туры китерү максатларында боерык бирәм:

1. 2019 елның 12 февралендәге 80-осн номерлы боерык белән расланган Әлки урманчылыгы урман хуҗалыгы регламентына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

3.3 бүлектәге 13 нче пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

| № п/п | Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре | Урманнардан файдаланудa чикләмәләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 13. | Сусаклагычлар һәм башка төрле ясалма су объектлары, шулай ук гидротехника корылмалары, елга портлары, причаллар төзү һәм эксплуатацияләү. | Тыюлыклы урман кишәрлекләрендә сусаклагычлар, башка төрле ясалма су объектлары, шулай ук гидротехника корылмалары, елга портлары, причаллар төзү һәм эксплуатацияләү тыела (РФ УК 107 ст. 2 өлешендәге 5 пункты). |

2. Әлеге боерык аны рәсми бастырып чыгарган көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Министр в.б. Ә.Н. Бәдертдинов